ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БОРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

26.10.2021 — 3

с. Татарское Бурнашево

Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлегенең Татар Борнашы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче ст., Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 нче елның 13 нче ноябренә 11.00 сәгатьтә Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Татар Борнашы авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынның беренче этабын билгеләргә.

2. 2021 нче елның 13 нче ноябренә 14.00 сәгатьтә Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Татар Борнашы авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынның икенче этабын билгеләргә.

3. Халык исемлеген бүлү территориаль билге буенча башкарыла.

1 этап: Татар Борнашы авылы, Беренче Май ур., Октябрь ур.

2 этап: Татар Борнашы авылы, Совет ур., Мәктәп ур., Яңа ур., Молодежная ур., Луговая ур., Имәнлек ур.

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Татар Борнашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 нче елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Татар Борнашы авылында юлларга вак таш җәю һәм төзекләндерү

«ӘЙЕ» «ЮК»

5. Халык җыеннары үткәрергә:

1 этап: Татар Борнашы авылының Беренче Май урамы буенча 48-нче номерлы йорт янында

2 этап: Татар Борнашы авылының Совет урамы буенча 58нче йорт янында.

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Борнаш авыл җирлеге башлыгы С.В.Бурукин